РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 2

2022 елның 14 феврале

Түбән Кама муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 48 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 23.1 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Түбән Кама муниципаль район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 48 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 4 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларында « , әлеге карар белән билгеләнгән» сүзләрен өстәргә;

карарның 2 нче кушымтасында таблицаның 4, 5 нче юлларында «1» санын «1 дән артык түгел» сүзләренә алмаштырырга;

карарга 5 нче кушымтаның 1 пунктында:

беренче абзацның икенче җөмләсендә «хезмәткәрне» сүзен «даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затны,» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга шулай ук Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм хезмәткәрләренең тулы вәкаләтле вәкилләре арасында төзелә торган социаль партнерлыкның территориаль-тармак килешүендә каралган нигезләр буенча һәм күләмнәрдә матди ярдәм түләнергә мөмкин.»;

карарга 17 нче кушымтаның 1 пунктына икенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга аларның гаризасы нигезендә шулай ук Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм хезмәткәрләренең тулы вәкаләтле вәкилләре арасында төзелә торган социаль партнерлыкның территориаль-тармак килешүендә каралган нигезләр буенча һәм күләмнәрдә матди ярдәм түләнергә мөмкин.»;

2. Түбән Кама муниципаль районы Советының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәргә.

3. «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль

бирәмлегенең бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

А.В.Умников